**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
(V чакырылыш)

V чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

«30» декабрь 2025 ел № 30 Урыссу ш.т.б.

Ютазы муниципаль районының
Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы
турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 10.09.2025 № 38 карары белән расланган Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2. Нигезләмәнең 1 пунктындагы 1.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Палата тарафыннан әзерләнгән карарлар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм күрсәтмәләре рәвешендә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелә.».

3. Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Хуббатова Алина Марат кызына Ютазы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының гамәлгә кую документларындагы үзгәрешләрне вәкаләтле дәүләт органында дәүләт теркәвенә алу чараларын үткәрергә вәкаләт бирергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 12 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Экология һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль
районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Р.М. Якупов
(8-85593) 2-42-05